**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 100 13 декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының
кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы №25-ФЗ Федераль законнарга, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» №56 карары;

- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе

турындагы нигезләмәне раслау турында» №56 карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 сентябрендәге № 37 карары.

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Н.Минһаҗев**